**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 17.03.2023** **№ 377**

**Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсен карау өчен гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 37, 39 статьяларына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына таянып, халыкның фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 13 апреленә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсен карау өчен, атап әйткәндә – Хәлиуллин Наил Фәритович милкендәге 2326 квадрат метр мәйданлы 16:16:320705:7529 кадастр номерлы җир кишәрлеген «торак төзелеше өчен» рөхсәт ителгән файдалану төреннән «Торак төзелешенә хезмәт күрсәтү» рөхсәт ителгән файдалану төренә, 14 сәгать 00 минутта, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка ав., Клуб ур., 1 й., Биектау авыл җирлеге администрациясе бинасында гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Кызыксынучы затка «Биектау хәбәрләре» газетасында җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрелү урыны һәм вакыты турында мәгълүматны бастырып чыгару белән бәйле чыгымнарны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясының 10 пункты нигезендә үз өстенә алырга.

3. Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кабул итүне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл. станциясе п., Совет ур., 13 йорт, 209 каб. адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр 2023 елның 03 мартыннан 2023 елның 13 апреленә кадәр чорда һәм шулай ук 2023 елның 13 апрелендә турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырырга.

4. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Маланин О.А. - Чернышевка авыл җирлеге башлыгы – Рәислек итүче;

2) Янбухтина А.Р. - Чернышевка авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре - Секретарь;

3) Дамоцев И.С. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге баш белгече;

4) Таҗиев К.А. - Чернышевка авыл җирлеге депутаты;

5) Шәйдуллин И.С. - Чернышевка авыл җирлеге депутаты.

5. Эш төркеменә катнаш кишәрлекләр милекчеләренә хәбәр итәргә (Форма кушымтада бирелә).

6. Эш төркеменә Биектау муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча беркетмә һәм бәяләмә әзерләп җибәрергә.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Хәбәрнамә

Хөрмәтле _________________________!

Сезгә _______ елның ______ ____ сәгатьтә ________________ авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: ________________________________________________________ адресы буенча, ________________ кадастр номерлы, ________________________________ милкендәге җир кишәрлегенең ___________________________________ мәсьәләсе буенча, Сез катнаш кишәрлек милекчесе булып торуыгыз сәбәпле, гавами тыңлаулар үткәрелүе турында хәбәр итәбез.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язма рәвештә кабул итү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл. станциясе п., Совет ур., 13 йорт, 209 каб., адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр _____ елның __________ нан ______ елның __________ кадәр чорда һәм шулай ук 2023 елның __________ турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырыла.

Гавами тыңлауларда катнашу өчен үзең белән паспорт алырга кирәк.

Барлык туган сораулар буенча 8-84365-23068 телефоны аша яисә Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл станциясе п., Кооператив ур., 5 й. адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

**Хәбәрнамәне алды:**

**Дата________________**

**Ф.И.А. _________________________________**

**Имза_______________________**